| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МАЙНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>МАЙНА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2026 с. Верх.Тат.Майна № 30

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советының 11.08.2023 ел, №47 «Татарстан Республикасы Алексеевск униципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Идел буе транспорт прокуратурасының 01.06.2026 № 23/1-2-2026 Протестын, ТР Алексеевск районы прокуратурасының 13.04.2026 № 02-01-16 бәяләмәсен үтәү йөзеннән, 2026 елның 25 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советының 11.08.2023 ел, № 47 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә(Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/),Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында(https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы** **А.В. Горбунова**

СОВЕТ МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Майна авыл җирлеге
Советының 26.08.2026 ел,
№ 30 карарына кушымта

**Бүлек 10. Юлларны карап тоту**

1) 38 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «һәм тимер юл транспортының контакт челтәрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

**Бүлек 15. Тышкы яктырту объектларын (чараларын) карап тоту**

2) 56 статьяның 1 өлешендә «тимер юл транспортының контакт челтәре таянычлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 56 статьяның 4 өлешендә «һәм тимер юл транспортының контакт челтәре таянычларында» сүзләрен төшереп калдырырга.

**Бүлек 21. Йорт хайваннарын һәм кошларын карап тоту**

4) 79 статьяның 4 өлешендәге 4 пунктында «4) торак массивлар, җәмәгать урыннары һәм социаль объектлар территориясендә хуҗалары булмаган хайваннарны ашату. Искәрмә – тыю җирле үзидарә органы тарафыннан хуҗасыз хайваннарны ашату өчен махсус оештырылган урыннарга кагылмый» сүзләрен төшереп калдырырга.